**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘЛӘКӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

12 ноябрь, 2021 ел Мәләкәс авылы № 18

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Калинин авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар жыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Мәләкәс авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының

## КАРАР БИРӘМ:

1. 2021елның 22 ноябренә 17:00 сәгаттә Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл жирлеге Калинин авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар жыенын билгеләргә.

2. Гражданнар жыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда яшәү урыны буенча Мәләкәс авыл жирлеге Калинин авылында территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000(бер мен) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- юлларны ремонтлау;

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Гражданнар жыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай районы, Калинин авылы, Үзәк урам, 17Б.

4. Халык жыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл жирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны авыл жирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Мәләкәс авыл җирлеге Башлыгы Ю.П.Васильев